# ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

**30 октябрь 2025 ел** **№2**

2026 елда Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Урманай авыл җирлеге Урманай торак пунктында гражданнардан үзара салым кертү турында

«Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль законның 45, 69 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елныц 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Урманай авыл җирлеге Урманай торак пунктында гражданнар җыены

**КАРАР ИТТЕ:**

1. 2026 елда Урманай авыл җирлегенең Урманай торак пункты территориясендә 1 төркем инвалидлардан, көндезге формада укучы студентлардан, махсус хәрби операциядә катнашучылардан, аларның гаилә әгъзаларыннан, Россия Федерациясе Кораллы Көчләрендә хәрби хезмәт узучы гражданнардан тыш, яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 500 сум күләмендә үзара салым кертергә.

2. Җыелган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча түбәндәге эшләрне башкаруга юнәлдерергә:

- халыкны су белән тәэмин итү һәм ташландык суларны агызу системаларын, су күтәрү манараларын, скважиналарны һәм су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, транспортлауны һәм халыкка су бирүне тәэмин итүче башка инженерлык корылмаларын ремонтлау (материаллар, җиһазлар сатып алу, авария хәлләрен бетерү, торбаларны алыштыру, контракт буенча эшләр өчен түләү);

- **традицион күмү урыннарын төзекләндерү, ремонт, коймалар кору** (зиратка материал сатып алу, киртәне урнаштыру, алмаштыру һәм буяу, тоташ эшли торган гербицид сатып алу һәм химик эшкәртү, үләнне чаптыру, агачларны һәм куакларны кисү, чүп-чарны җыю).

3. Әлеге карарны, кабул ителгәннән соң 10 көн эчендә, Урманай авыл җирлеге мәгълүмати стендларында һәм Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында (http://aznakaevo.tatarstan.ru), хокукый мәгълүматның рәсми сайтында (http://pravo.tatarstan.ru) урнаштыру юлы белән игълан итәргә.

Халык җыенында рәислек итүче, Азнакай муниципаль районы Урманай авыл җирлеге башлыгы: Э.Р.Абдуллина